Республика Татарстан

Исполнительный комитет
Менделеевского
муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль
районы
башкарма комитеты

РАСПОРЯЖЕНИЕ БОЕРЫК

____20.03.2024_____ Менделеевск ш. № ____206______

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
территориясендә кар чистарту буенча
эшләр үткәрүне оештыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, сәнәгать билгеләнешендәге биналарның, торак фондының, башка корылмаларның җимерелүләрен кисәтү, халыкның кар ишелү һәм түбәләрдәге боз сөңгеләре төшү аркасында килеп чыккан бәхетсезлек очракларын кимету һәм гадәттән тыш хәлләрне булдырмау өчен чаралар күрү максатларында, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты
БОЕРЫК БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы территориясендә урнашкан биналар һәм корылмалар җитәкчеләренә, оешмалар, учреждениеләр җитәкчеләренә, милекчеләргә (арендаторларга) тәкъдим итәргә:

1.1. Өйрәтелгән һәм инструктаж узган оешма хезмәткәрләрен җәлеп итеп, түбәне кар-боз массаларыннан чистарту буенча кичектергесез чаралар күрергә.

1.2. Түбәне кардан һәм боз сөңгеләреннән чистарту эшләрен башкарганда куркынычсызлык техникасы таләпләрен үтәүне шәхси контрольгә алырга.

1.3. Түбәләрдәге кар һәм боз сөңгеләре төшү нәтиҗәсендә халык арасында имгәнү ихтималын кимету чараларын башкарырга:

1.3.1. Чистарту урыннарында җәяүлеләр хәрәкәтен тыя торган билгеләрне һәм киртәләрне куярга.

1.3.2. Җәяүлеләрне һәм автотранспорт йөртүчеләрне кисәтү өчен саклау зонасында кизү торучыларны чыгарырга.

2. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты идарәләре ведомство буйсынуындагы учреждениеләрнең җитәкчеләрен кар һәм боз сәңгеләреннән түбәләрне вакытында чистартуны системалы контрольдә тотарга.

3. Әлеге күрсәтмәнең үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Р.Р.Искәндәров